| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
05.05.2023

КАРАР
№ 443

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021нче елның 7нче июнендәге 526нчы номерлы «Контракт хезмәте турындагы нигезләмәне (регламентны) раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә

карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2021нче елның 7нче июнендәге 526нчы номерлы «Контракт хезмәте турындагы нигезләмәне (регламентны) раслау хакында» карарының 1 нче кушымтасы 2.3 пунктына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.3. Контракт хезмәтен контракт хезмәте җитәкчесе - Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җитәкли».

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2021нче елның 7нче июнендәге 526нчы номерлы «Контракт хезмәте турындагы нигезләмәне (регламентны) раслау хакында» карарының 1 нче кушымтасына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының аерым структур бүлекчәсен төземичә генә контракт хезмәте функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы хезмәткәрләрнең даими составын раслап, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының https://nurlat рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. tatarstan.ru/.

Җитәкче З.Р. Сәйфетдинова

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.05.2023 № 443 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының, аерым структур бүлекчәсен төземичә генә, контракт хезмәте функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәүче хезмәткәрләрнең даими составы:

| | Вазыйфасы |
|---|---|
| Контракт хезмәте җитәкчесе | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе |
| Контракт хезмәте әгъзалары | Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль заказлар бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының торак сәясәте һәм коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының ЗАГС бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмати иминлек бүлеге башлыгы |